КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 8 февраль г.Казань № 69

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында» 2023 ел, 11 март, 231 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бер мәртәбә субсидия бирү турында» 2022 ел, 18 февраль, 137 нче карары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында» 2023 ел, 11 март, 231 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм хәрби хәрәкәтләр инвалидларына (алга таба – сугыш инвалидлары);

инвалид балаларны караучы затларга.»;

3 пунктта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү тәртибе турындагынигезләмәдә:

1.1 пунктта:

икенче абзацка «Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм хәрби хәрәкәтләр инвалидларына (алга таба – сугыш инвалидлары), инвалид балаларны караучы затлар» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацка «сугыш инвалидлары, инвалид балаларны караучы затлар» сүзләрен өстәргә;

2.1 пунктның унынчы абзацында «категориясенә» сүзенә кадәр «, сугыш инвалидлары» сүзләрен өстәргә, «Бөек Ватан сугышы ветераннарына» сүзләренә кадәр «сугыш инвалидларына,» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Үзәк бүлеге ведомствоара рәсми сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә субсидия бирү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматны ала:

яшәү урыны буенча теркәлү турында;

инвалидлык һәм аның төркеме булу турында (булганда);

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

никахлашуны (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

үлемне дәүләт теркәвенә алу турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокукы теркәлгән торак урынга милек хокукы турында;

балага опека билгеләү турында;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында; ата-ана хокукларын чикләүне гамәлдән чыгару турында белешмә, баланың гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда аны тартып алу турында белешмә;

хезмәт бурычларын яки башка бурычларны үтәгән өчен акчалата бүләкләү (стимул бирү характерындагы түләүләрне кертеп), башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт, гражданлык-хокукый шартнамә кысаларында гамәлләр кылу өчен акчалата бүләкләү турында;

Россия Федерациясе законнары һәм (яки) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган пенсия, пособиеләр һәм башка шундый түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминият түләүләре һәм компенсация характерындагы түләүләр суммалары турында;

керемнәр исәпкә алына торган исәп-хисап чорында эшкә сәләтсез затларны карауны гамәлгә ашыру турында.

инвалид баланы карауны гамәлгә ашыру турында.

Гариза бирүчеләр яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәгә ия документларны үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә тапшырырга хокуклы.»;

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән категорияләргә туры килмәве;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазларын сатып алуга бер мәртәбә субсидия бирү турында» 2022 ел, 18 февраль, 137 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин